**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 ноябрь № 875

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасын төзү турында» 2016 ел, 5 май, 283 нче карары белән расланган «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасы уставына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасын төзү турында» 2016 ел, 5 май, 283 нче карары белән расланган «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасы уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 нче пунктның беренче абзацына һәм 2.1 нче пунктка «, шулай ук Татарстан Республикасын һәм аның мөмкинлекләрен Россия Федерациясе территориясендә дә, аннан читтә дә эшлекле туризм базарына чыгару һәм эре конгресс-күргәзмә һәм эшлекле төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара чараларны Татарстан Республикасына җәлеп итү.» сүзләрен өстәргә;

2.2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасын һәм аның мөмкинлекләрен эшлекле туризм базарына чыгару буенча чаралар үткәрү;

эре конгресс-күргәзмә һәм эшлекле төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара чараларны Татарстан Республикасына җәлеп итү.».

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков